**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР

____________                                                                 _______

Актаныш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме турында

Районда террорчылыкны профилактикалау өлкәсендә халыкның билгеле бер категорияләренә, аны гамәлгә ашыру формаларына һәм ысулларына юнәлтелгән мәгълүмати сәясәтнең төп юнәлешләрен билгеләү, террорчылык һәм экстремизм күренешләренә бәйле ситуацияләрдә оператив мәгълүмат белән җавап бирүне оештыру, террорчылыкка каршы һәм экстремистик юнәлештәге даими агарту чараларын әзерләү һәм уздыру максатларында, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме составын расларга (1 нче кушымта).
2. Актаныш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме турында нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Терроризмга һәм экстремизмга мәгълүмати каршы тору буенча районда АТК эшче төркеме турында» 2015 елның 28 маендагы ПГ-24 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы порталында түбәндәге: http//aktanysh.tatarstan.ru. адрес буенча, басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе И.Р.Вахитовка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы                                                                 Э.Н.Фәттахов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
______________ № __
1 нче кушымта

Террорчылык һәм экстремизмга каршы көрәш буенча
мәгълүмати-пропаганда төркеме составы

Габдулхаев И.И. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе;

Вахитов И.Р – муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе, төркем рәисе урынбасары;

Усманов Р.М. - муниципаль район Советының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы, төркем секретаре;

Төркем әгъзалары:

Гыймадиев А. Р. - «Татмедиа» АҖ филиалы «Актаныш мәгълүмат-мөхәррият үзәге» директоры (килешү буенча);

Шакирова Р.М. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;

Гәрәева А. А – Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-агарту эшләре бүлегенең баш белгече;

Вәлиев Л. Ә. – Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Мортазин Р. Р – ТР ДНИ Актаныш муниципаль районы имам-мөхтәсибе (килешү буенча);

Латыпов А. Р. - ТР буенча Россия ФКХИ хезмәткәре (килешү буенча);

Гайнуллин И. М. - Актаныш районы буенча Эчке эшләр бүлегенең полиция башлыгы урынбасары (оператив эш буенча), полиция майоры (килешү буенча).

Мөхәммәдиева И.М. - "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге " муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча).

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
______________ № ___
2 нче кушымта

Актаныш муниципаль районының террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Актаныш муниципаль районында терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмати-пропаганда төркеменең (алга таба - эшче төркеме) максатын, бурычларын һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актларына, республика законнарына һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хокукый актларына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Эшче төркем Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында терроризмны профилактикалау өлкәсендә мәгълүмати сәясәтнең төп юнәлешләрен, халыкның билгеле бер категорияләренә, аны тормышка ашыру формаларына һәм методларына, терроризм һәм экстремизм күренешләренә бәйле ситуацияләрдә оператив мәгълүмати җавап бирүне оештыру, терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге даими агарту чараларын әзерләү һәм үткәрү максатларында оештырылды.

4. Мәгълүмати-пропаганда төркеменең бурычлары:

4.1. Актаныш муниципаль районы территориясендә терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу.

4.2. Актаныш муниципаль районында терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендәге вәзгыятькә йогынты ясаучы сәяси һәм башка процесслар мониторингы.

4.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати-пропаганда материалларын әзерләү һәм алга этәрү.

4.4. Иҗтимагый һәм дини оешмаларга тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту максатларында толерантлыкны, милләтара һәм конфессияара диалогны үстерүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын һәм проектларны гамәлгә ашыруда уңай шартлар тудыру.

4.5. Терроризмны, экстремизмны профилактикалау, аларның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү өлкәсендә Актаныш муниципаль районы оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлекне оештыру.

4.6. Дини-сәяси экстремизм идеологиясенең җинаятьчел асылын аңлату максатларында Интернет челтәрендә даими максатчан эш оештыру.

4.7. Россия Федерациясе законнарында каралган терроризмны, экстремизмны профилактикалау, аларның күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү өлкәсендәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

4.8. Терроризм һәм экстремистлык идеологиясенең таралуын профилактикалау. Халыкка терроризм һәм экстремизмның иҗтимагый асылын аңлату.

4.9. Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча үткәрелә торган дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында халыкка мәгълүмат бирү.

4.10. Массакүләм мәгълүмат чараларында терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге материалларны яктырту.

4.11. Халыкның радикальләшү дәрәҗәсен киметү һәм террорчылык һәм экстремистлык идеологиясе таралу алшартларын бетерү өчен шартлар тудыру.

4.12. Террорчылык күренешләренә сәбәп булырга мөмкин булган этно-конфессиональ конфликтларга мәгълүмати йогынты.

4.13. Мәгълүмати янаулар чагылышларына каршы тору:

- террорчылык янавына халыкның уяулыгын арттыру һәм террорчылык күренешләрен булдырмау эшендә хокук саклау органнары һәм махсус хезмәтләр белән актив хезмәттәшлек итү зарурилыгы;

- терроризмга каршы тору буенча Россия Федерациясенең дәүләт сәясәте кысаларында яшьләр белән тәрбия эшләре алып бару.

4.14. Террорчылык һәм экстремистлык күренешләренә сәбәп булырга мөмкин булган этноконфессиональ конфликтлы хәлләрне локальләштерү чараларында катнашу.

4.14. Террористик янауда халыкның уяулыгын арттыруга ярдәм итү һәм терроризм һәм экстремистлык күренешләрен булдырмау эшендә хокук саклау органнары һәм махсус хезмәтләр белән актив хезмәттәшлек итү:

- терроризм һәм экстремизм күренешләренә бәйле ситуацияләргә оператив мәгълүмати җавап бирү буенча комплекслы чаралар эшләү һәм тормышка ашыру;

- терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге агарту чараларын үткәрү өчен методик кулланмалар әзерләү.

5. Мәгълүмати-пропаганда төркеменең эш тәртибе.

5.1. Эшче төркем рәисе:

- эшче төркем эшчәнлеген координацияли;
- эшче төркем утырышларын билгели;
- эшче төркем карарларына кул куя.

5.2. Эшче төркем рәисе урынбасары рәис булмаганда яисә аның кушуы буенча эшче төркем рәисе вазыйфаларын башкара.

5.3. Эшче төркем секретаре:

- эшче төркем утырышлары беркетмәсен алып бара һәм имзалый;
- утырышларның вакыты һәм урыны турында эшче төркем әгъзаларына хәбәр итә;
- эшче төркемгә кергән материалларны һәм мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып бара.

5.4. Эшче төркем утырышлары эшче төркем рәисе раслаган график буенча өч айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә уздырыла.

5.5. Утырышның вакыты һәм көн тәртибе эшче төркем әгъзалары игътибарына аны үткәрүгә биш көннән дә соңга калмыйча җиткерелә.

5.6. Утырыш эшче төркем әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

5.7. Утырыш барышында протокол алып барыла, ул рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана.

5.8. Утырыш нәтиҗәләре буенча эшче төркем карарлары кабул ителә.

5.9. Эшче төркем карарлары утырышта катнашучы күпчелек эшче төркем әгъзалары хуплаган очракта кабул ителгән дип санала.

5.10. Карарлар кабул ителгәннән соң, бер атна эчендә, кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

5.11. Эшче төркем карарлары тәкъдим итү характерына ия.

6. Эшче төркем хокуклары.

Үз бурычларын хәл итү өчен мәгълүмати-пропаганда төркеме хокуклы:

- үз компетенциясе кысаларында террорчылыкны профилактикалау, аның күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм бетерү буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка дәүләт органнары,

оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыруга, координацияләүгә һәм камилләштерүгә кагылышлы карарлар кабул итәргә;

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

- мәгълүмати хәбәрләрне һәм материалларны Актаныш муниципаль районының рәсми порталына урнаштырырга;

-массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек вәкилләре өчен очрашулар, матбугат конференцияләре, брифинглар, презентацияләр, Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия әгъзалары, Актаныш муниципаль районы учреждениеләре һәм предприятиеләре җитәкчеләре, чакырылган экспертлар һәм белгечләр, иҗтимагый оешмалар, дини берләшмәләр һ. б. катнашында «түгәрәк өстәлләр» оештырырга;

- Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия әгъзаларын җәмәгатьчелек алдында, предприятиеләрдә, иҗтимагый һәм мәгариф оешмаларында чыгышларга җәлеп итәргә;

- терроризмга каршы юнәлештәге тышкы реклама чараларын һәм күрсәтмә агитация продукциясе (плакатлар, листовкалар, календарьлар һ. б.) әзерләүне башлап җибәрергә;

- билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затлардан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында терроризмны профилактикалау өлкәсендә мәгълүмати сәясәтне гамәлгә ашыруга кагылышлы мәгълүматны соратып алырга;

7. Эшче төркем үз эшчәнлеген планлы нигездә башкара. Төркемнең эш планы Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия рәисе тарафыннан раслана. Эшче төркем Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссиягә үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хәбәр итә. Актаныш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия төркеме эш нәтиҗәләре буенча билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиягә хәбәр итә.

8. Актаныш муниципаль районының терроризмга каршы көрәш һәм экстремизмга каршы тору буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме составы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.